| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2022 п.г.т.Алексеевское № 467

**2023 елга Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы»муниципаль берәмлегендә балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 15 статьясы 1 өлеше 11 пункты, «Татарстан Республикасында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты Алексеевск муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмә нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2023 нче елга расларга:

Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы»муниципаль берәмлегендә балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик,социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын (Кушымта); туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик,социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм

культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының программаларын тормышка ашыруның норматив чыгымнарына төзәтү коэффициентын 0,65 күләмендә.

2. Алексеевск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Леденцов О. Н.) тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслау;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын гамәлдә булу чорында кире карау, бер үк вакытта балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бергә, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
27.10.2022 № 467карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы»муниципаль берәмлегендә балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы баларга өстәмә белем бүрү оешмаларында балаларга туристлык туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем программасының юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, бер укучыга елына сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | Өченче һәм алдагы уку елы |
| Нәфис-эстетик | шәһәр җирлеге | 7 851 | 14 539 | 17 447 |
| | авыл җирлеге | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 7 750 | 14 351 | 17 222 |
| | авыл җирлеге | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗад | шәһәр җирлеге | 8 155 | 15 101 | 18 121 |
| | авыл җирлеге | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Экологик-биологик | шәһәр җирлеге | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль -педагогик | шәһәр җирлеге | 7 547 | 13 977 | 16 772 |
| | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль-экономик | шәһәр җирлеге | 7 547 | 13 977 | 16 772 |
| | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Фәнни-табигый | шәһәр җирлеге | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |